СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная д.2 а ,д..Нижние Аты
Арский муниципальный район,422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2а йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы,422016

Тел. (84366) 50-7-35 факс (84366) 507-35 E-mail: Sat.Ars@tatar.ru.

## Урта Аты авыл җирлеге Советы
## КАРАРЫ

24 июль 2026 ел №22

### Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган территория чикләрен билгеләү турында

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, "Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында" 2014 елның 02 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Урта Аты авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлегенең ирекле халык дружинасы төзелергә һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкин булган, үз эченә Урта Аты , Тубэн Аты,Урта Сэрдэ ,Кылачы авылы торак пунктларын алган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге чикләрен территория чикләре дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- "Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында" 2014 елның 17 декабрендәге 73 номерлы;
- "Урта Аты авыл җирлеге Советының"Халык дружинасы эшчәнлеге территориясе чиген билгеләү турында" 2018 елның 02 февралендәге 52/1 номерлы.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Батталова